КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 8 апрель г.Казань № 274

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының авыл җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының авыл җирлекләренә грантлар турында» 2013 ел, 29 август, 614 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 11 ноябрь, 866 нчы; 2014 ел, 8 май, 304 нче; 2014 ел, 17 май, 330 нчы; 2014 ел, 26 декабрь, 1032 нче; 2016 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 733 нче; 2018 ел, 20 март, 159 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар турында »;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү өчен ел саен Республика конкурсын үткәрү турында «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе тәкъдимен кабул итәргә (алга таба – Конкурс).»;

2 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибе.»

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының авыл җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составы»;

оештыру комитеты составыннан Н.А.Таркаеваны, О.А.Кисаповaны чыгарырга;

оештыру комитеты составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе Айрат Дөлфәт улы Шәмсиевне (килешү буенча);

Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары Алла Леонидовна Анфимованы;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының авыл җирлекләренә грантлар бирү өчен республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты турындагы нигезләмәдә (алга таба – Нигезләмә):

Нигезләмәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты турында нигезләмә»;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) Татарстан РеспубликасыМинистрлар Кабинеты тарафыннан Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын (алга таба – Конкурс) оештыру һәм үткәрү максатларында Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибе (ага таба – Тәртип) нигезендә бирелә.»;

2.1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бу Тәртип нигезендә үткәрелгән Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү нәтиҗәләренә анализ ясау;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының авыл җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибендә (алга таба – Тәртип):

Тәртип исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибе

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә республика конкурсын (алга таба – Конкурс) ел саен оештыру һәм үткәрү процедурасын, шулай ук Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү бирү һәм файдалану тәртибен билгели.»;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Грант – Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре тормышын турыдан-туры тәэмин итү объектларының матди-техник базасын ныгыту, авыл җирлекләрендә урнашкан торак пунктларның социаль инфраструктура объектларын булдыру һәм аларны тышкы яктан төзекләндерү, Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең башка социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итү өчен Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә Конкурс йомгаклары буенча бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;

социаль әһәмиятле мәсьәләләр – аларны «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, ФЗ-131 нче Федераль законның 14 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2007 ел, 28 июль, ТРЗ-45 нче Татарстан Республикасы Законының 15 статьясы нигезендә хәл итү, тулы кыйммәтле яшәүне, сәламәтлекне саклауны, белем бирүне, тәрбия бирүне, мәдәният үсешен тәэмин итү, авыл җирлекләренең тарихый күренешен саклап калу, торак пунктларда яшәүне һәм эшләүне стимуллаштыру, янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, шулай ук башка иҗтимагый ихтыяҗларны канәгатьләндерү максатларында, авыл җирлекләренең тормыш эшчәнлеге шартларын яхшыртуга китерә торган мәсьәләләр;

Конкурста катнашучылар – Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре;

грант алучылар – Конкурста җиңүчеләр дип танылган Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре.»;

3.1 пунктның беренче – өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Конкурсның төп максатлары:

Татарстан Республикасы авыл халкы тормышының сыйфатын яхшырту буенча Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнары эшчәнлеген стимуллаштыру;

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең социаль әһәмиятле мәсьәләләрен хәл итү;»;

4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Конкурс үткәрелгәндә Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре җирле үзидарә органнарының түбәндәге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре буенча бәяләнә:

1) Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге халкының табигый үсеше;

2) Татарстан Республикасы авыл җирлегенең һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегенең бер кешегә салым һәм салым булмаган керемнәре (мең сум);

3) Татарстан Республикасы авыл җирлегендә һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны (100 кешегә);

4) Татарстан Республикасы авыл җирлегендә эре мөгезле терлекнең баш саны (башлар);

5) Татарстан Республикасы авыл җирлегендз һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә бер кешегә торак файдалануга кертү, кв.метр;

6) өсте каты ябулы юллар озынлыгының Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге юлларының гомуми озынлыгындагы өлеше (процент);

7) Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районнарының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге территориясендә кылынган җинаятьләр саны (100 кешегә).»;

4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Һәр муниципаль районнан җиңүчеләр саны түбәндәгеләрдән чыгып билгеләнә:

4.7.1. Авыл җирлекләре өчен – тиешле муниципаль район составына керүче авыл җирлекләре халкы саныннан:

ике җиңүче – авыл җирлекләре халкының саны 22 мең кешегә кадәр булганда;

өч җиңүче – авыл җирлекләре халкының саны 22 мең кешедән артыграк булганда.

4.7.2. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре өчен – Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге халкы санына карап:

бер җиңүче – Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге халкы саны 5 меңгә кадәр булган очракта;

бер җиңүче – Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге халкы саны 5 меңнән 11 меңгә кадәр булган очракта;

бер җиңүче – Татарстан Республикасы муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге халкы саны 11 мең кешедән артып китә.»;

4.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.8. Конкурска йомгаклар, бу Тәртипкә һәм бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы методикага таянып, Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлегенең нәтиҗәләрен комплекслы бәяләү нигезендә ясала.»;

4.8 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшчәнлекләренең нәтиҗәлелегенә иң югары бәяләр алган Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре Конкурсның җиңүчеләре дип танылa.»;

4.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9. Конкурста җиңүче, Конкурс үткәрүгә һәм аның йомгаклары буенча җиңүче дип танылуга өч ел вакыт узгач, Конкурста катнаша ала.

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә оештырылган шәһәр җирлекләре арасында оештырылган Конкурста җиңүче аның нәтиҗәләре буенча ул җиңүче дип танылган Конкурс узганнан соң ике елдан да иртәрәк булмаган Конкурста катнаша ала.»;

5.6 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү буенча Татарстан Республикасы муниципаль районының чыгым йөкләмәсен билгеле торган Татарстан Республикасы муниципаль районының билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән муниципаль хокук акты булу-булмавы;»;

Тәртипкә 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү

**МЕТОДИКАСЫ**

1. Татарстан Республикасы авыл җирлекләренең һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген комплекслы бәяләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$К= (И_{п1} + И_{п2} + ...П_{пп}) / n,$$

монда:

$И_{п1}$ – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең беренче күрсәткече мәгънәсенең җыелма индексы;

$И_{п2}$ – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең икенче күрсәткече мәгънәсенең җыелма индексы;

$П_{пп}$ – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең n күрсәткече мәгънәсенең җыелма индексы.

2. Җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең җыелма индексы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$И_{п} = 0,5 \times И_{ст} + 0,5 \times И_{со},$$

монда:

$И_{п}$ – Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районның административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең җыелма индексы;

$И_{ст}$ – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткече үсешенең уртача темпы индексы;

$И_{со}$ – җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең уртача күләме индексы.

3. Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районның административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткече үсешенең урта темпы индексы түбәндәгечә билгеләнә:

а) зур мәгънә зур нәтиҗәлелекне чагылдыра торган күрсәткеч индексына карата түбәндәге формула буенча:

$$И_{ст} = (Т – Т_{мин}) / (Т_{макс} – Т_{мин}),$$

монда:

Т – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр

тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткече үсешенең уртача темпы мәгънәсе;

$Т_{мин}$ – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткече үсешенең уртача темпының минимум мәгънәсе;

$Т_{макс}$ – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлеге һәм муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткече үсешенең уртача темпының максимум мәгънәсе;

б) зур мәгънә аз нәтиҗәлелекне чагылдыра торган күрсәткеч индексына карата түбәндәге формула буенча:

$$И_{ст} = (Т_{макс} – Т_{мин}) / (Т_{макс} – Т_{мин}).$$

4. Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең уртача күләме индексы түбәндәгечә билгеләнә:

а) зур күрсәткеч зур нәтиҗәлелекне чагылдыра торган күрсәткеч индексына карата түбәндәге формула буенча:

$$И_{со} = (О – О_{мин}) / (О_{макс} – О_{мин}),$$

монда:

О – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең уртача күләме мәгънәсе;

$О_{мин}$ – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең уртача күләменең минимум мәгънәсе;

$О_{макс}$ – хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткеченең уртача күләменең максимум мәгънәсе;

б) зур күрсәткеч аз нәтиҗәлелекне чагылдыра торган күрсәткеч индексына карата түбәндәге формула буенча:

$$И_{со} = (О_{макс} – О) / (О_{макс} – О_{мин}).$$

5. Хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга авыл җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре үсешенең уртача темпы түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$T_j = \sqrt{\frac{П_j}{П_{j-1}} \times \frac{П_{j-1}}{П_{j-2}} \times \frac{П_{j-2}}{П_{j-3}}},$$

монда:

$П_j$ – хисап чорына Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткече мәгънәсе;

$П_{j-1}$ – хисап елына кадәр 1 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткече мәгънәсе;

$П_{j-2}$ – бер ел өчен һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткече мәгънәсе;

$П_{j-3}$ – бер ел өчен һәм хисап елына кадәр 3 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткече мәгънәсе.

6. Хисап елына һәм хисап елына кадәр 2 елга Татарстан Республикасы авыл җирлекләре һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләре эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткеченең уртача күләме мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$О = (П_j + П_{j-1} + П_{j-2}) / 3.$$

7. Хисап елы өчен Татарстан Республикасы авыл җирлекләре яки муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренең эшчәнлеге нәтиҗәлелегенең бер яисә берничә күрсәткечләре булмаган очракта, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелегә күрсәткеченең тиешле индексына нуль мәгънәсе билгеләнә.»;

Тәртипкә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирү һәм алардан файдалану тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы авыл җирлекләренә һәм муниципаль районының административ үзәкләре булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлекләренә грантлар бирүгә еллык республика конкурсын үткәрү өчен кирәкле мәгълүмат исемлеге

| Т/с | Мәгълүмат төре (авыл җирлекләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге күрсәткече) | Күрсәткечнең мәгънәсен хисаплап чыгару | Мәгълүмат кертү өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә даими яшәүче халыкның еллык уртача саны, кеше | Календарь елы башына һәм ахырына халыкның уртача арифметик саны: $Ч=Ч_{баш}+Ч_{ахыры}/2$ | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |
| 2. | Бер кешегә Татарстан Республикасы авыл җирлегенең яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегенең салым һәм салым булмаган керемнәре, мең сум | $V=A/B$,<br>монда:<br>А – Татарстан Республикасы авыл җирлегенең яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегенең салым һәм салым булмаган керемнәре күләме, сум;<br>В – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә һәм муниципаль | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә даими яшәүче халык саны, кеше | |
| 3. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә (100 кешегә) | V=A/B x 100,<br>монда:<br>A – салым органнарында теркәү һәм яңадан теркәү узган индивидуаль эшмәкәрләр, икътисадый актив урта, кече һәм микро-предприятиеләр саны;<br>B – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә даими яшәүче халык саны, кеше | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча), җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |
| 4. | Татарстан Республикасы авыл җирлегендә мөгезле эре терлекнең баш саны, баш | V – авыл җирлегендә мөгезле эре терлекнең баш саны, баш | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |
| 5. | Бер яшәүчегә Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән | V=A/B,<br>монда:<br>A – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге | Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | шәһәр җирлегендә торак (индивидуаль торак төзелеше) сафка кертү, кв.метр | булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә торакның гомуми мәйданы, кв.метр;<br>B – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә даими яшәүче халык саны, кеше | |
| 6. | Татарстан Республикасы авыл җирлеге яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге юлларының гомуми озынлыгында каты өслекле юллар озынлыгы өлеше (процент) | V=A/B x 100,<br>монда:<br>A – Татарстан Республикасы авыл җирлегенең яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге каты өслекле юллары озынлыгы, километр;<br>B – Татарстан Республикасы авыл җирлеге яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге юлларының гомуми озынлыгы, километр | «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы, җирле үзидарә органнары (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 7. | Татарстан Республикасы авыл җирлеге яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге территориясендә кылынган җинаятьләр саны (100 кешегә) | V=A/B x 100,<br>монда:<br>A – Татарстан Республикасы авыл яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлеге территориясендә кылынган җинаятьләр саны,<br>B – Татарстан Республикасы авыл җирлегендә или городского яки муниципаль районының административ үзәге булмаган шәһәр тибындагы поселок нигезендә төзелгән шәһәр җирлегендә даими яшәүче халык саны, кеше | «Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре советы» ассоциациясе (килешү буенча), Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы (килешү буенча)». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин